РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.12.2024** Кукмара ш. **№ 695**

«2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары, «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясына таянып, Кукмара муниципаль районында авыл хуҗалыгы продукциясенең көндәшлеккә сәләтлелеген арттыру максатларында **карар бирәм:**

1. Кушымта итеп бирелгән «2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасын расларга (алга таба – Программа).

2. Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет формалаштырганда финанслауны тәэмин итәргә.

3. Программаны башкаручыларга Программаны вакытында һәм тулысынча үтәүне тәэмин итәргә киңәш итәргә.

4. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 03 декабрендәге 695 номерлы карарына кушымта

## «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» ПРОГРАММАСЫ

### 1. «2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон.<br><br>«Авыл хуҗалыгын үстерүнең һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары<br><br>«Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары |
| Программаның заказчысы һәм эшләүчесе | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты,<br>Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара |

| | |
|---|---|
| | муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| Программаның максаты | - эчке һәм тышкы базарларда җирле авыл хуҗалыгы продукциясенең көндәшлеккә сәләтлелеген арттыру;<br>- эшмәкәрлекне үстерү, тармакның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру өчен уңайлы мохит тудыру;<br>- агросәнәгать комплексы товар җитештерүчеләренең финанс тотрыклылыгын тәэмин итү;<br>- авыл хуҗалыгында җир һәм башка табигать ресурсларын торгызу һәм файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру, җитештерүне экологияләштерү;<br>- авыл территорияләрен тотрыклы үстерү;<br>- яшь белгечләрне авылда калдыруны стимуллаштырып, аграр белемле белгечләрне җәлеп итү. |
| Программаның бурычлары | - авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерүне үстерүне стимуллаштыру;<br>- туфракның уңдырышлылыгын саклау һәм торгызу өчен шартлар тудыру, авыл хуҗалыгы җирләрен мелиорацияләүне үстерү;<br>- кече хуҗалыкларга ярдәм итү;<br>- агросәнәгать комплексын техник һәм технологик модернизацияләү, инвестиция эшчәнлеген стимуллаштыру;<br>- авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең керемлелеген арттыру, киңәйтелгән җитештерү өчен оештыру-икътисадый шартлар тудыру;<br>- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән нәтиҗәле файдалануны стимуллаштыру:<br>- агросәнәгать комплексы өлкәсендә мәгълүмат белән тәэмин итү системасын камилләштерү;<br>- агросәнәгать комплексы өлкәсендә идарәне камилләштерү;<br>- авыл халкының эш белән тәэмин ителешен, |

| | |
|---|---|
| | тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | Программа 2024 – 2026 еллар дәвамында гамәлгә ашырыла. |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | «Программа» ны финанслау күләме – 610,9 млн сум, шул исәптән:<br>2024 ел – 211,9 млн сум<br>2025 ел – 199,2 млн сум<br>2026 ел – 199,8 млн сум<br>«Программа»ны финанслау чыганаклары<br>- Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты – 531,1 млн сум;<br>- Кукмара муниципаль районының җирле бюджеты – 4,8 млн сум,<br>- бюджеттан тыш акчалар – 75 млн сум. |
| Ярдәмче программалар исемлеге | Үсемлекчелекне, терлекчелекне үстерү<br>Авыл хуҗалыгы предприятиеләрен техник һәм технологик модернизацияләү<br>Хуҗалык итүнең кече формаларын (КФХ, шәхси ярдәмче хуҗалык) үстерүне стимуллаштыру<br>Социаль төзекләндерү һәм авыл халкына ярдәм итү<br>Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүче хезмәткәрләргә түләү |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү индексы – 2026 елда 2024 ел дәрәҗәсенә карата 104 %.<br>- хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру – 2026 елда 2024 ел дәрәҗәсенә карата 104 %<br>- авыл хуҗалыгы оешмалары буенча уртача айлык хезмәт хакын арттыру – 2026 елда 2024 ел дәрәҗәсенә карата 115 %. |

## 2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгының хәзерге торышы

Кукмара муниципаль районының аграр секторы халык хуҗалыгының әһәмиятле өлкәсен тәшкил итә һәм районның гына түгел, Татарстан Республикасының да икътисадында мөһим роль уйный. Агросәнәгать комплексын үстерү районның икътисадый һәм социаль өлкәсендә стратегик өстенлекләрнең берсе булды һәм булып кала бирә. Кукмара муниципаль районы икътисадын үстерү юлында төп элементларның берсе – хуҗалык итүнең кече һәм

урта формаларын үстерү. Хәзерге вакытта сөт, ит җитештерү, бөртекле һәм техник культуралар үстерү белән төрле милек формасындагы 13 эре предприятие һәм 80 нән артык фермер хуҗалыгы шөгыльләнә, аларда районның эшкә сәләтле 1,7 мең кешесе эшли. Авыл хуҗалыгы җитештерүендә эшләүчеләрнең уртача айлык хезмәт хакы 50,1 мең сум тәшкил итә. Район икътисады структурасында кече һәм урта эшмәкәрлек зур өлешне алып тора, алар үз керемнәренең төп өлешен сөт һәм ит җитештерүдән, шулай ук авыл хуҗалыгы культураларын үстерүдән алалар. Авыл хуҗалыгы оешмалары белән беррәттән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүдә шәхси ярдәмче хуҗалыклар да зур роль уйный. 29 авыл җирлегенең барлык авылларында да гражданнарның шәхси хуҗалыкларыннан сөт җыю оештырылган, алар белән 14 тән артык шәхси хуҗалык, КФХ шөгыльләнә.

Районда сөтчелек комплексларын төзү һәм терлекчелекне цифрлаштыру буенча актив эш алып барыла. 2012 елдан 2024 елга кадәр 13,5 мең терлеккә исәпләнгән заманча саву заллары булган 12 сөтчелек комплексы төзелде һәм файдалануга тапшырылды.

Бүгенге көндә 4,4 мең терлеккә исәпләнгән 3 сөтчелек комплексы төзелә («Милка» ҖЧҖ – 2400, «Урал» АХҖК – 1000 һәм «Вахитово» ҖЧҖ – 1000). 2025 елда сөт заводы төзелә башлый.

Икътисадның аграр секторында зур уңышларга карамастан, якын киләчәктә хәл ителергә тиешле кичектергесез проблемалар да бар. Бу юнәлешләрнең берсе – хуҗалыкларның техник базасын ныгыту. Әлеге юнәлештә Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы программалары буенча, Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән берлектә, кредитлар һәм үз акчаларын җәлеп итү юлы белән тыгыз эш алып барыла. Район авыл хуҗалыгы паркын яңартуга –куәтле тракторлар, чәчү комплекслары, ашлык җыю комбайннары һәм азык әзерләү техникасы сатып алуга мохтаҗ. Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү буенча алдынгы технологияләрне гамәлгә кертү зарур. Терлекчелектә нәселле терлек сатып алу эшен дәвам итәргә кирәк, сыерларның югары продуктив токымнарыннан башмак таналар үрчетүне көчәйтергә кирәк. Акча булмау шулай ук терлекчелек фермалары өчен яңа җайланмалар сатып алырга мөмкинлек бирми.

## 3. «Программа»ны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

2024 – 2026 елларга Программаның максатлары:

- эчке һәм тышкы базарларда җирле авыл хуҗалыгы продукциясенең көндәшлеккә сәләтлелеген арттыру;
- эшмәкәрлекне үстерү, тармакның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру өчен уңайлы мохит тудыру;
- агросәнәгать комплексы товар җитештерүчеләренең финанс тотрыклылыгын тәэмин итү;
- авыл хуҗалыгында җир һәм башка табигать ресурсларын торгызу һәм файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;
- авыл территорияләрен тотрыклы үстерү;

- яшь белгечләрне авылда калдыруны стимуллаштырып, аграр белемле белгечләрне җәлеп итү.

Әлеге максатларга ирешү өчен, Программада түбәндәге бурычларны хәл итү карала:

1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерүне үстерүне стимуллаштыру;

2. Туфракның уңдырышлылыгын саклау һәм торгызу өчен шартлар тудыру, авыл хуҗалыгы җирләрен мелиорацияләүне үстерү;

3. Кече хуҗалыкларга ярдәм итү;

4. Агросәнәгать комплексын техник һәм технологик модернизацияләү, инвестиция эшчәнлеген стимуллаштыру;

5. Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең керемлелеген арттыру, киңәйтелгән җитештерү өчен оештыру-икътисадый шартлар тудыру;

6. Агросәнәгать комплексы өлкәсендә мәгълүмат белән тәэмин итү системасын камилләштерү;

7. Агросәнәгать комплексы өлкәсендә идарәне камилләштерү;

8. Авыл халкының эш белән тәэмин ителешен, тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү;

9. Йомгаклау күрсәткечләре һәм камиллеккә омтылыш буенча бүләкләп, эре предприятиеләрнең баш белгечләрен нәтиҗәле хезмәткә стимуллаштыру.

## 4. 2024 – 2026 елларга агросәнәгать комплексы үсеше фаразы

2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районының агросәнәгать комплексы үсеше динамикасы төрле юнәлештәге факторлар тәэсирендә формалашачак. Бер яктан, соңгы елларда агросәнәгать җитештерүенең тотрыклылыгын арттыру буенча күрелгән чаралар чагылачак, икенче яктан, санкцияләр нәтиҗәләренә бәйле рәвештә катлаулы макроикътисадый вәзгыять сакланачак, бу икътисадның аграр секторын тотрыклы һәм динамикалы үстерү өчен куркыныч ихтималын арттыра.

Үсемлекчелектә яңа буын тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына, минераль ашламалар куллануның нәтиҗәлелеген арттыруга һәм үсемлекләрне өстәмә тукландыру һәм яклау эшләрен башкаруга нигезләнгән интенсив технологияләрне үзләштерергә кирәк.

Терлекчелектә терлекчелек тармагының продуктивлыгын һәм тотрыклылыгын арттыруга, ныклы азык базасы булдыруга, терлекләрнең сакланышын яхшыртуга һәм баш санын арттыруга, тотрыклы иминлекне тәэмин итүгә, шулай ук ит һәм сөт җитештерүне тизләтелгән арттыруга беренчел әһәмият бирелә, бу продуктларны халыкның куллану дәрәҗәсен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Терлекчелек продукциясен җитештерү күләмен арттыру түбәндәгеләр хисабына планлаштырыла:

- заманча сөтчелек комплекслары төзеп һәм терлекчелек фермаларын модернизацияләп, инвесторлар җәлеп итеп;

- нәселле терлек сатып алу;

- терлекләрне ашату дәрәҗәсен күтәрү һәм тоту шартларын яхшырту;

- терлекләрнең продуктлылыгын арттыру.

«Программа»ның авыл хуҗалыгын үстерү фаразы аның төп күрсәткечләре (индикаторлары) кыйммәтләренә ирешүнең кирәклегенә һәм актуальлегенә нигезләнә

**2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы буенча агросәнәгать комплексын социаль-икътисадый үстерүнең төп күрсәткечләре.**

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
|---|---|---|---|---|
| Авыл хуҗалыгы оешмалары һәм КФХ буенча тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе (гамәлдәге бәя) | млн сум | 9736 | 9930 | 10129 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү индексы | % | 123,6 | 102 | 102 |
| Натураль чагылышта продукция җитештерү: | тонна | | | |
| - бөртеклеләрдән тулаем җыем, берәмлек | мең тонна | 312,8 | 315,0 | 315 |
| - сөт | мең тонна | 174,0 | 190,0 | 207 |
| - ит | мең тонна | 10,1 | 10,8 | 11,3 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан акчалата керем | млн сум | 7972 | 8131 | 8293 |
| 1 хезмәткәргә уртача айлык хезмәт хакы | сум | 50 152 | 55 100 | 57855 |
| Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеге | мең сум | 5 767 | 5882 | 6000 |

- авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү индексы 2026 елда 102 % тәшкил итәчәк, ә 2024 ел дәрәҗәсенә карата – 104 %.

- хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру – 2026 елда 2024 ел дәрәҗәсенә карата 104 %.

- авыл хуҗалыгында (авыл хуҗалыгы оешмалары буенча) уртача айлык хезмәт хакын арттыру – 2026 елда 2024 ел дәрәҗәсенә карата 115 %.

## 5. Төп чараларга һәм ярдәмче программаларга характеристика

Ярдәмче программалар һәм аларга кертелгән төп чаралар агымдагы һәм перспективалы мөһим максатларны һәм бурычларны хәл итүгә, авыл җирлекләрен тотрыклы үстерүгә юнәлдерелгән үзара бәйле чаралар комплексын тәшкил итә.

«Үсемлекчелекнең ярдәмче тармагын, үсемлекчелек продукциясен эшкәртүне һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасына түбәндәге төп чаралар керә:

- туфракның уңдырышлылыгын күтәрү;
- культуралы үсемлекләрнең генетик ресурсларын саклап калу һәм алардан нәтиҗәле файдалану;
- төп авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүне үстерүне стимуллаштыру;
- үсемлекчелек ярдәмче тармагына кредит бирү;
- авыл хуҗалыгын иминиятләштерү;
- үсемлекчелек продукциясен эшкәртүне үстерү.

Ярдәмче программаның максатчан индикаторлары сыйфатында үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү күләмнәре, азык культуралары чәчү мәйданнары, ашлык җитештерүнең чагыштырма күләме файдаланыла.

«Терлекчелекнең ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртүне һәм сатуны үстерү» ярдәмче программасында түбәндәге төп чаралар билгеләнде:

- нәселле терлекчелек;
- маточный сыерларның баш санын югары продуктив токымнар белән яңарту;
- ит һәм сөт терлекчелеген үстерү;
- ветеринария өлкәсендәге чаралар;
- терлекчелек продукциясен эшкәртүне үстерү;
- терлекчелек ярдәмче тармагына кредит бирү;
- авыл хуҗалыгын иминиятләштерү.

Барлык категория хуҗалыкларда сөт, сугымга терлек һәм кош-корт җитештерү күләмнәре, җитештерелгән ит һәм сөт продукциясенең чагыштырма күләме ярдәмче программаны гамәлгә ашыру индикаторлары булып тора.

«Техник һәм технологик модернизацияләү» ярдәмче программасына түбәндәге төп чаралар керә:

- авыл хуҗалыгы техникасы паркын яңарту;

- авыл хуҗалыгы җитештерүендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру;

- авыл хуҗалыгы оешмаларында авыл хуҗалыгы консультациясе системасын үстерү.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру индикаторлары булып, авыл хуҗалыгы оешмалары тарафыннан техниканың төп төрләрен сатып алу күләмнәре, 100 га чәчүлек мәйданнарына карата куәте һәм энергия белән тәэмин ителеш тора.

«Кече хуҗалыкларга ярдәм» ярдәмче программасы кече эшмәкәрлеккә ярдәм өлкәсендә дәүләт һәм район чараларын, төп юнәлешләрне дә кертеп, дәвам итүдән һәм киңәйтүдән гыйбарәт:

- эш башлаучы крестьян (фермер) хуҗалыкларына ярдәм;

- крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү;

- хуҗалык итүнең кече формаларына озак сроклы, урта сроклы һәм кыска сроклы кредитлар буенча процент ставкасын субсидияләү;

- авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына дәүләт ярдәме;

- кооперативларның мини-сөт парклары территориясендә мини-фермалар төзүенә ярдәм итү;

Ярдәмче программа индикаторлары сыйфатында түбәндәгеләр каралган:

- яңа төзелгән крестьян (фермер) хуҗалыклары саны;

- алар төзегән яисә реконструкцияләнгән гаилә терлекчелек фермалары саны;

- хуҗалык итүнең кече формалары алган субсидияләнә торган кредитлар һәм заемнар күләмнәре;

- авыл хуҗалыгы һәм кулланучылар кооперативларының керемнәре үсеше;

- мини-сөт парклары территориясендә төзелгән мини-фермалар саны

«Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасына түбәндәге чаралар керә:

- авыл халкының торак шартларын яхшырту һәм яшь гаиләләрне, яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү;

- авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү;

- авыл тормышына уңай мөнәсәбәт формалаштыру.

Чараларны гамәлгә ашыру индикаторлары:

- авыл җирендә яшәүче гражданнар, шул исәптән яшь гаиләләр һәм белгечләр өчен торак тапшыру (сатып алу);

- авыл территорияләренең социаль өлкәсендәге төп объектларны кулланышка тапшыру; - республика программаларын гамәлгә ашыруга грант ярдәме алган авыл җирлекләре саны.

## 6. Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары

Программаны күп каналлы принцип буенча финанслау планлаштырыла: федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Кукмара муниципаль районы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына.

| Чыгымнар чыганаклары | Финанслау күләме, млн сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән, еллар буенча | | |
| | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| ТРның берләштерелгән бюджеты | 531,1 | 135,5 | 197,5 | 198,1 |
| Кукмара муниципаль районы бюджеты (алга таба – МБ) | 4,8 | 1,4 | 1,7 | 1,7 |
| Башка чыганаклар (алга таба – бюджеттан тыш фондлар) | 75,0 | 75,0 | | |

## 7. Программаны тормышка ашыру механизмы

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Программа чараларын гамәлгә ашыруның җаваплы башкаручысы (координаторы) булып тора. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетында Программа чараларын гамәлгә ашыру буенча комиссия төзелә.

Кукмара муниципаль районы территориясендәге барлык милек рәвешләрендәге авыл хуҗалыгы формированиеләре уртак башкаручылар булып торалар, Программаның үз компетенцияләрендәге бурычларын хәл итү һәм чараларын үтәү өчен җаваплы.

Ел дәвамында Программа чараларының барышы һәм нәтиҗәләре Кукмара район Советы утырышында карала. Ел саен хисаптан соң килүче 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетында төзелгән комиссия Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белгечләре катнашында Программа чараларының барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерли.

«2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасына кушымта

**Программа чаралары исемлеге**

| | Чараларның атамалары | Башкаручы | Финанслау чыганаклары | Еллар буенча чыгымнар суммасы, млн сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | Барлыгы |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | 1. Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерүне стимуллаштыру. | | | | | | |
| 1.1 | Сыерлар һәм кәҗәләр асрауга субсидия бирү | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | 15,3 | 15,3 | 15,3 | 45,9 |
| 1.3 | Кече сөтчелек фермасы төзү | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | 0,6 | 1,5 | 1,5 | 3,6 |
| 1.4 | Эш башлаучы фермерларга (КФХларга) дәүләт ярдәменә грантлар һәм (яисә) бердәм вакытлыча ярдәм күрсәтү | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | | | | |
| 1.5 | Гаилә терлекчелек фермаларын (КФХ) үстерүгә грантлар бирү | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | | | | |
| 1.6 | Шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарга 3 | МСХиП РТ, УСХиП | ТРның берләштерелгән | 0,7 | 0,8 | 0,8 | 2,3 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яшьтән зуррак бияләр тотуга субсидияләр бирү | (килешү буенча) | бюджеты | | | | |
| 1.7 | Мини-сөт парклары территориясендә мини-сөт фермалары төзүгә кооперативларны субсидияләү | МСХиП РТ | ТРның берләштерелгән бюджеты | 20,0 | 40,0 | 40,0 | 100,0 |
| | 2. Үсемлекчелекне үстерү | | | | | | |
| 2.1 | Үсемлекчелек өлкәсендә гектар ярдәм күрсәтүгә субсидияләр (ташламалы ашламалар, үсемлекләрне саклау чаралары сатып алганда ярдәм) | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | | | | |
| 2.2 | Элиталы орлыклар сатып алуга субсидияләр бирү юлы белән орлык материалының репродуктив составын яхшырту | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | 0,1 | 0,5 | 0,5 | 1,1 |
| 2.3 | Минераль ашламалар сатып алу чыгымнары өлешен каплауны субсидияләү. | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | 33,1 | 35,0 | 35,0 | 103,1 |
| 2.4 | Авыл хуҗалыгы техникасы, җайланмалар, конструкцияләр, махсус автотранспорт сатып алуга субсидияләр бирү | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | 27,7 | 64,4 | 65 | 157,1 |
| | 3. Терлекчелекне үстерү | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1 | Нәселле терлекчелеккә ярдәм | МСХиП РТ<br>КМР Башкарма комитеты | ТРның берләштерелгән бюджеты<br>МБ | 38<br>75 | 40 | 40 | 118<br>75 |
| 3.2 | 1 литр сатылган сөткә субсидия бирү | МСХиП РТ, УСХиП (килешү буенча) | ТРның берләштерелгән бюджеты | | | | |
| 4.1 | Язгы кыр эшләрендә, азык әзерләү, урып-җыю һәм көзге кыр эшләрендә эшләүче хезмәткәрләрне бүләкләү | МСХиП РТ, УСХиП, КМР БК | ТРның берләштерелгән бюджеты<br>МБ | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,6 |
| 4.2 | Ел саен конкурслар үткәрү:<br>- машина белән сыер саву операторлары һәм терлекләр үрчетү технологлары конкурсы; | УСХиП, КМР БК | МБ | | | | |
| 4.3 | Ел йомгаклары һәм Алдынгылар слеты йомгаклары буенча ел саен «Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләре көне» бәйрәмнәрен үткәрү | УСХиП, КМР БК | МБ | | | | |
| 4.4 | Ел саен «Сабантуй» милли бәйрәмен үткәрү | УСХиП, КМР БК | МБ<br>ВБ | | | | |
| 4.5 | «Кукмара районы агросәнагать комплексының иң яхшы белгече» конкурсы кысаларында авыл | УСХиП, КМР БК | МБ | 1,2 | 1,5 | 1,5 | 4,2 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хуҗалыгы предприятиеләренең баш белгечләрен бүләкләү. | | | | | | |

Кулланылган кыскартулар:

КМР БК – Кукмарамуниципаль районы Башкарма комитеты

МСХиП РТ – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

УСХиП – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе

ФБ – Федераль бюджет

РБ – Республика бюджеты

ҖБ – җирле бюджет

ВБ – бюджеттан тыш фондлар